**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**«26» август 2022 ел** **№ 123**

**Нурлат муниципаль районының Финанс - бюджет палатасы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 24 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Уставы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы турындагы Норлат муниципаль район Советының 14.03.2016 ел, № 28 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең 5.1 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Палатаны районның җирле үзидарәсенең вазыйфаи заты булган рәис җитәкли, Палата эшчәнлеге белән җитәкчелек итә һәм аның эшен оештыра.

Палата рәисе Нурлат муниципаль районы Башлыгы тәкъдиме белән Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфасына билгеләнә. Палата рәисе Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле вәкиле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирә торган затлар арасыннан вазыйфага билгеләнә.

Татарстан Республикасы финанс органы катнашында палата рәисе вазыйфасын биләүгә кандидатларның квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасы финанс органының әлеге тикшерүне үткәрүдә катнашу тәртибе Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

Палата рәисе вазыйфасы буенча Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары булып санала».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырырга.

3. Бу карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Советының җирле үзидарәгә һәм авыл хуҗалыгына ярдәм буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы Рәисе А.С. Әхмәтшин